# Җиләк-җимешләр һәм яшелчәләр.

Алар ничек үсәләр?

# Яз көне алмагач чәчәк ата.



# Җәй көне алмагачта алмалар өлгерә.




Көз көне алмаларны җыялар. Бу алма. Алма яшел.



Җәй көне түтәлдә кыяр үсә.



Бу кыярлар. Кыяр яшел.
Ул яшелчә.



Җәй көне бакчаларда кара карлыган өлгерә.



Бу - кара карлыган җиләкләре. Җиләкләр кара.



Җәй көне бакчаларда кура җиләге өлгерә.



Бу – кура җиләге. Кура җиләге кызыл төстә.



Болай кабак үсә. Ул көз көне өлгерә. Кабак – яшелчә.



Бу – кызыл карлыган җиләкләре. Кызыл карлыган куакта үсә, җәй көне өлгерә.



Бу - сырганак.Сырганак агачта үсә, көз көне өлгерә.



# Болай чия үсә.



Бу - чия җиләкләре,
алар кызыл төстә.

